| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.12.2024 № 1470

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының "Нурлат шәһәре территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында" 2022 елның 14 июнендәге 62 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатларында, «Акционер җәмгыятьләр турында» 1995 елның 26 декабрендәге 208-ФЗ номерлы закон, «Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында» 1998 елның 08 февралендәге 14-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Хуҗалык җәмгыятьләренең мөһер мәҗбүрилеген бетерү өлешендә «Аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2015 елның 06 апрелендәге 82-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 июнендәге 625 номерлы карары белән расланган Нурлат шәһәре территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзегән өчен түләү күләмен сату буенча аукцион оештыру һәм уздыру турындагы нигезләмәгә, 8.4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«8.4.2. гариза бирүче - юридик зат исеменнән гамәлләр башкаруга зат вәкаләтләрен раслый торган документ (физик затны гариза бирүче исеменнән ышанычнамәсез эш итү хокукына ия булган вазыйфага билгеләү яисә сайлау турында карар йә билгеләү турында боерык күчермәсе (алга таба - җитәкче). Әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән башка зат эш итсә, гаризада шулай ук мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәлләр башкаруга мөрәҗәгать итүче җитәкчесе (юридик затлар өчен) яисә әлеге җитәкче вәкаләт биргән зат тарафыннан имзаланган ышанычнамә йә мондый ышанычнамәнең нотариаль таныкланган күчермәсе булырга тиеш. Әгәр күрсәтелгән ышанычнамә мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле җитәкчесе тарафыннан имзаланган булса, гаризада шулай ук мондый затның вәкаләтләрен раслый торган документ булырга тиеш;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат

порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында (nurlat.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Г. Гыйниятуллин